**Татарстан Республикасы**
# ЗАКОНЫ

**Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерү, аларны саклау, кире кайтару, күчергән һәм саклаган өчен чыгымнарны түләү тәртибе турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 26 апрелендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законны җайга салу предметы**

Әлеге Закон Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә административ хокук бозулар турындагы эшләр башкаруны тәэмин итү чараларын куллану кысаларында тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерү, аларны саклау, кире кайтару, шулай ук күрсәтелгән транспорт чараларын күчергән һәм саклаган өчен чыгымнарны түләү тәртибен билгели.

2 статья. **Төп төшенчәләр**

1. Әлеге Закон максатларында түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

1) транспорт чаралары – двигателенең эшләү күләме 50 куб сантиметрдан артык булган һәм максималь конструктив тизлеге сәгатенә 50 километрдан артык булган автомототранспорт чаралары, тракторлар, башка үзйөрешле юл-төзелеш машиналары һәм бүтән машиналар, аларның дәүләт теркәве узарга тиешле прицеплары, трамвайлар һәм троллейбуслар, аз сыешлы суднолар;

2) махсуслаштырылган урын – тоткарланган транспорт чараларын саклауның махсус бүлеп бирелгән саклана торган урыны;

3) махсуслаштырылган транспорт чарасы – башка транспорт чараларын йөртү өчен билгеләнгән транспорт чарасы.

2. Әлеге Законда кулланыла торган бүтән төшенчәләр гамәлдәге законнарда билгеләнгән мәгънәләрендә файдаланыла.

3 статья. **Транспорт чарасын тоткарлау турында беркетмә**

1. Тоткарланган транспорт чарасын транспорт чарасын тоткарлау турындагы карарны үтәүче затка тапшыру Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы нигезендә тиешле административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан төзелә торган транспорт чарасын тоткарлау турындагы беркетмә (алга таба – беркетмә) белән рәсмиләштерелә.

2. Беркетмәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) транспорт чарасын тоткарлау турындагы карарны кабул итү датасы, вакыты, урыны, нигезе;

2) беркетмә төзегән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы;

3) транспорт чарасы турында белешмәләр;

4) үзенә карата административ хокук бозу турындагы эш буенча эшләр башкаруны тәэмин итүнең тиешле чарасы кулланылган зат турындагы белешмәләр;

5) органның (учреждениенең, оешманың) исеме, транспорт чарасын тоткарлау турындагы карарны үтәүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы.

3. Беркетмәгә транспорт чарасы салонындагы (кабинасындагы, кузовындагы) мөлкәт исемлеге, транспорт чарасының тышкы салына торган комплектлау әйберләре исемлеге, транспорт чарасының тышкы зыян килгән урыннары исемлеге кертелә.

4. Беркетмәгә аны төзегән вазыйфаи зат һәм үзенә карата административ хокук бозу турындагы эш буенча эшләр башкаруны тәэмин итүнең тиешле чарасы кулланылган зат имза сала.

5. Тоткарланган транспорт чарасының хуҗасы яисә аннан файдалану яисә аның белән эш итү хокукына ия зат (алга таба – аны йөртүче) булмаганда, беркетмә ике пүнәтәй катнашында төзелә.

6. Үзенә карата административ хокук бозу турындагы эш буенча эшләр башкаруны тәэмин итүнең тиешле чарасы кулланылган зат беркетмәгә имза салудан баш тарткан очракта, бу хакта беркетмәгә тиешенчә язып куела.

7. Беркетмә күчермәсе үзенә карата административ хокук бозу турындагы эш буенча эшләр башкаруны тәэмин итүнең тиешле чарасы кулланылган затка һәм транспорт чарасын тоткарлау турындагы карарны үтәүче затка тапшырыла.

4 статья. **Транспорт чарасын йөртүчегә үзе югында транспорт чарасын тоткарлау турында мәгълүмат бирү**

Транспорт чарасын йөртүчегә үзе югында транспорт чарасын тоткарлау турында мәгълүмат бирү Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5 статья. **Тоткарланган транспорт чарасын күчерү**

1. Тоткарланган транспорт чарасын йөртүче, пүнәтәйләр, шулай ук беркетмә төзегән вазыйфаи зат таләбе буенча транспорт чарасын тоткарлау турындагы

карарны үтәүче зат тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерү гамәлләрен башкару хокукына ышанычнамә күрсәтә.

2. Тоткарланган транспорт чарасын тоткарлау сәбәбен бетергәнче алга таба саклау өчен махсуслаштырылган урынга күчерү төре һәм алымы, тоткарланган транспорт чарасының техник характеристикаларыннан чыгып, Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.

3. "Инвалид" тану тамгасы куелган тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга күчерү турында карар кабул итү инвалидларга дәүләт ярдәме һәм аларны социаль яклау өлкәсендәге законнар нормаларын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

4. Тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга күчергәндә, транспорт чарасын тоткарлау турындагы карарны үтәүче затның кулында беркетмәнең күчермәсе булырга тиеш.

5. Тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга күчерер алдыннан транспорт чарасын тоткарлау турындагы карарны үтәүче зат тоткарланган транспорт чарасын йөртүче барында, ә ул булмаганда ике пүнәтәй барында транспорт чарасына керү конструктив рәвештә каралган барлык урыннарны, шул исәптән ишекләр, люклар, форточкалар, төяү-бушату капкалары, транспорт чарасының мотор һәм багаж бүлемтекләренә керүне конструктив тәэмин итүче элементларны, мөһерләп бикләп куя.

6. Транспорт чарасын тоткарлау турындагы карарны үтәүче зат тоткарланган транспорт чарасын күчерүгә кабул итеп алуы турында беркетмәдә тамга сала, тоткарланган транспорт чарасын мөһерләп бикләп куелган пломбалы ярлыкларның номерларын һәм транспорт чарасының алга таба саклану урынын күрсәтә.

## 6 статья. **Тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга урнаштыру**

1. Тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга урнаштырганда, транспорт чарасын тоткарлау турындагы карарны үтәүче зат һәм махсуслаштырылган урынның вазыйфаи заты тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга кабул итү-тапшыру акты төзи.

2. Тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга кабул итү-тапшыру актында түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) махсуслаштырылган урынның исеме (булган очракта) һәм урнашкан урыны;

2) транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга урнаштыру датасы һәм вакыты;

3) транспорт чарасы турында беркетмә нигезендә белешмәләр;

4) транспорт чарасы мөһерләп бикләп куелган пломбалы ярлыкларның номерлары;

5) транспорт чарасы салонындагы (кабинасындагы, кузовындагы) мөлкәт исемлеге, транспорт чарасының тышкы салына торган комплектлау әйберләре исемлеге, транспорт чарасының тышкы зыян килгән урыннары исемлеге;

6) транспорт чарасын тоткарлау турындагы карарны үтәүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы;

7) транспорт чарасын саклауга кабул итеп алган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы, аның имзасы.

3. Тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга кабул итү-тапшыру актына беркетмәнең күчермәсе кушып бирелә.

7 статья. **Махсуслаштырылган урынга урнаштырылган тоткарланган транспорт чараларын исәпкә алу**

1. Махсуслаштырылган урында тоткарланган транспорт чараларының исәбе алып барыла.

2. Тоткарланган транспорт чарасын күчерү, махсуслаштырылган урынга урнаштыру, алга таба саклау һәм бирү өчен нигез булып торган документлар исәпкә алынырга һәм сакланырга тиеш.

8 статья. **Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урында саклауга кабул итеп алу һәм аннан бирү вакыты**

Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урында саклауга кабул итеп алу һәм аннан бирү тәүлек буена гамәлгә ашырыла.

9 статья. **Махсуслаштырылган урындагы тоткарланган транспорт чарасына аны йөртүченең керә алуы**

1. Тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урында саклаган вакытта транспорт чарасын йөртүче аңа керергә хокуклы.

2. Тоткарланган транспорт чарасына аны йөртүче кергән һәр очрак турында акт (алга таба – керү турындагы акт) төзелә, керү факты турында шулай ук тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга кабул итү-тапшыру актында тамга куела.

3. Керү турындагы актта түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) керү датасы, вакыты, урыны;

2) транспорт чарасы турында беркетмә нигезендә белешмәләр;

3) транспорт чарасы мөһерләп бикләп куелган пломбалы ярлыклар номерлары;

4) транспорт чарасын йөртүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме;

5) тоткарланган транспорт чарасына аны йөртүче кергән вакытта булган, махсуслаштырылган урында транспорт чараларын саклау өчен җаваплы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы;

6) транспорт чарасыннан аны йөртүче тарафыннан алынган әйберләр, предметлар, документлар турында белешмәләр.

4. Бикләп куелган мөһер урыны транспорт чарасына керү аркасында бозылган транспорт чарасы, аны йөртүче шунда булганда, яңадан мөһерләп бикләп

куелырга тиеш. Транспорт чарасын яңадан мөһерләп бикләп кую факты керү турындагы актта күрсәтелә.

5. Керү турындагы актка транспорт чарасын йөртүче һәм тоткарланган транспорт чарасына аны йөртүче кергән вакытта булган, махсуслаштырылган урында транспорт чарасын саклау өчен җаваплы зат имза сала. Керү турындагы актның күчермәсе транспорт чарасын йөртүчегә тапшырыла.

10 статья. **Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урында саклауга куела торган таләпләр**

1. Тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урында саклау барышында тоткарланган транспорт чарасына өченче затлар кереп йөри алмаслык чаралар күрелергә тиеш.

2. Тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урында саклау чорында түбәндәгеләр тыела:

1) транспорт чарасының двигателен кабызу;

2) пломбалы ярлыкларны өзү.

3. Тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урын территориясендә күчерү тулысынча яисә өлешчә махсуслаштырылган транспорт чарасына төяү йә тактырып буксирга алу ярдәмендә генә рөхсәт ителә.

4. Тоткарланган транспорт чарасының махсуслаштырылган урын территориясендә двигателен кабызып күчерү транспорт чарасын аны йөртүчегә биргәндә генә рөхсәт ителә.

5. Махсуслаштырылган урынга урнаштырылган тоткарланган транспорт чараларының сакланышына яный торган, әлеге шартларда каршы тора алмаслык табигый яисә техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр (җиңеп чыга алмаслык көч) килеп чыкканда, мондый хәлләрне булдырмауга яисә алардан килгән зыяннарны бетерүгә вәкаләтле затлар әлеге статьяның 1 – 4 өлешләрендә билгеләнгән таләпләрдән чигенергә хокуклы.

6. Мондый чигенү сәбәпләре турында тиешле тамга тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга кабул итү-тапшыру актында күрсәтелергә тиеш.

11 статья. **Тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урында саклау срогы**

1. Тоткарланган транспорт чарасын саклау срогы аны махсуслаштырылган урынга урнаштырган вакыттан алып хуҗасына биргән вакытка кадәр исәпләнә.

2. Тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга урнаштыру вакыты тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга урнаштыруның тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга кабул итү-тапшыру актында күрсәтелгән вакыты була.

3. Транспорт чарасын махсуслаштырылган урыннан бирү вакыты транспорт чарасын махсуслаштырылган урыннан бирү турындагы актта күрсәтелгән вакыт була.

4. Саклау срогы сәгатьләрдә исәпләнә.

12 статья. **Тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга күчерү чыгымнарын һәм тоткарланган транспорт чарасын саклау чыгымнарын түләү**

1. Тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга күчерү (төяү-бушату эшләрен дә кертеп) чыгымнары һәм тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга урнаштырган вакыттан алып махсуслаштырылган урыннан биреп җибәргәнчегә кадәр саклау чыгымнары түләнергә тиеш.

2. Махсуслаштырылган транспорт чарасына транспорт чарасын төягәннән соң һәм махсуслаштырылган урынга саклауга урнаштырганчы транспорт чарасын тоткарлау сәбәбе бетерелгән очракта, төяү-бушату эшләре чыгымнары түләнергә тиеш.

3. Тоткарланган транспорт чарасын күчерү һәм саклау чыгымнарын түләү исәбенә акчаларны махсуслаштырылган урында кабул итеп алу тәүлек дәвамында башкарыла.

4. Төяү-бушату эшләре чыгымнарын түләү исәбенә акчалар кабул итеп алу тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга саклауга урнаштыру факты булмаганда, транспорт чарасын тоткарлау турындагы карарны үтәүче зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Тоткарланган транспорт чарасын саклаган өчен түләү аның махсуслаштырылган урында торган һәр тулы сәгате өчен алына.

6. Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын күчергән һәм махсуслаштырылган урыннарда саклаган өчен түләү күләмнәре Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бәяләрне дәүләт көйләве өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан раслана.

13 статья. **Транспорт чарасын аны йөртүчегә бирү**

1. Транспорт чарасын аны йөртүчегә бирү Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 27.13 статьясындагы 3 өлеше нигезендә транспорт чарасын тоткарлауны туктату турында карар кабул итәргә вәкаләтле вазыйфаи затның язма рөхсәте нигезендә башкарыла. Вәкаләтле вазыйфаи затның рөхсәттәге имзасы эчке эшләрнең тиешле органы яисә аз сыешлы суднолар буенча дәүләт инспекциясе органының түгәрәк мөһере белән таныклана.

2. Транспорт чарасын йөртүче, аны бирү турында мөрәҗәгать иткәндә, транспорт чарасына тиешле теркәү документларын күрсәтә.

3. Транспорт чарасын махсуслаштырылган урыннан алганда, аны йөртүче, тоткарланган транспорт чаралары сакланышы өчен җаваплы зат шунда булганда, үз транспорт чарасын карап-тикшереп чыга.

4. Махсуслаштырылган урыннан транспорт чарасын бирү турында акт төзелә. Транспорт чарасын бирү турындагы актта (алга таба – бирү турында акт) түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) махсуслаштырылган урыннан транспорт чарасын бирүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы;

2) транспорт чарасын йөртүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме;

3) әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән, транспорт чарасын бирү өчен нигез булып торган язма рөхсәт турындагы белешмәләр;

4) транспорт чарасына карата күрсәтелгән теркәү документлары турындагы белешмәләр;

5) транспорт чарасы турында беркетмә нигезендәге белешмәләр;

6) тоткарланган транспорт чарасын мөһерләп бикләп куюөчен кулланылган пломбалы ярлыклар номерлары, аларның бөтенлеге турында белешмәләр;

7) махсуслаштырылган урыннан транспорт чарасын бирү датасы һәм вакыты, махсуслаштырылган урынның исеме (булган очракта) һәм урнашкан урыны.

5. Күчергәндә һәм (яисә) саклаганда транспорт чарасының сакланышын тәэмин итүгә карата транспорт чарасын йөртүченең дәгъвалары булмаганда, кабул итү-тапшыру актында бу хакта тиешле тамга ясала. Күчергәндә һәм (яисә) саклаганда транспорт чарасының сакланышын тәэмин итүгә карата транспорт чарасын йөртүченең дәгъвалары килеп чыкканда, бу хакта транспорт чарасын йөртүче бирү турында актта күрсәтә. Бирү турында актның күчермәсе транспорт чарасын йөртүчегә тапшырыла.

6. Беркетмәдә махсуслаштырылган урында транспорт чараларын саклау өчен җаваплы зат транспорт чарасын тиешле халәттә (транспорт чарасының тоткарлау мизгеленә булган халәтендә) бирү турында язып куя, транспорт чарасын йөртүче имза сала.

14 статья. **Эчке эшләр органнары һәм аз сыешлы суднолар буенча дәүләт инспекциясе органнары вазыйфаи затларының транспорт чарасын тоткарлау турындагы карарны үтәүче, махсуслаштырылган урында транспорт чараларын саклау һәм аларны бирү өчен җаваплы затлар белән хезмәттәшлеге**

Эчке эшләр органнары һәм аз сыешлы суднолар буенча дәүләт инспекциясе органнары вазыйфаи затларының транспорт чарасын тоткарлау турындагы карарны үтәүче, махсуслаштырылган урында транспорт чараларын саклау һәм аларны бирү өчен җаваплы затлар белән хезмәттәшлеге шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла.

15 статья. **Тоткарланган транспорт чарасын күчергәндә һәм (яисә) махсуслаштырылган урында саклаганда аңа китерелгән зыянны каплау**

Тоткарланган транспорт чарасын күчергәндә һәм (яисә) махсуслаштырылган урында саклаганда аңа китерелгән зыян Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә каплана.

16 статья. **Әлеге Закон белән билгеләнгән таләпләрне үтәмәгән өчен җаваплылык**

Әлеге Законда билгеләнгән таләпләрне үтәмәгән өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылык билгеләнә.

17 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон 2012 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2012 елның 17 мае
№ 24-ТРЗ